ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 май, 2021 ел № 7/5

Шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 22 октябрендәге 2/11 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 399 һәм 403 статьялары, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 22 октябрендәге 2/11 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2017 елның 15 декабрендәге 21/8, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/7, 2019 елның 7 октябрендәге 33/7, 2019 елның 6 декабрендәге 34/8, 2020 елның 21 февралендәге 37/7 номерлы Карарлары редакциясендә), 4 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1) 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган салым түләүчеләр (ата-аналар, уллыкка (кызлыкка) бала алган ата-аналар), опекуннар һәм попечительләр (тәрбиягә бала алган, патронат ата-аналар);».

2. Әлеге Карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ